| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.08.2021 г.Лениногорск № 780/1

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип тану турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында нигезләмәге раслау хакында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары, бинаның (күпфатирлы йортның) урынын торак бина дип тану турындагы нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә, күпфатирлы йортның авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле таләпләренә туры килүен бәяләү турында ведомствоара комиссия бәяләмәсе (2021 елның 28 июлендәге 212 номерлы беркетмә) нигезендә, тәкъдим ителгән документлар: «ТР БТИ» АҖ тарафыннан әзерләнгән «ТР, Лениногорск муниципаль районы, Лениногорск шәһәре, Горький ур., 35А йорт адресы буенча урнашкан күпфатирлы торак йортның техник торышын бәяләү буенча ТЗ-001/21 техник бәяләмә» һәм Күпфатирлы йортның торакны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында 2021 елның 28 июлендәге 29 номерлы билгеләнгән күпфатирлы йортның таләпләргә туры килүен бәяләү турында бәяләмә нигезендә, авария хәлендә дип танылган авария хәлендәге йортлар реестрын формалаштыру максатыннан, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Аерым торучы бинаны - Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәренең Горький урамы 35А номерлы күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип танырга.

2. Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетында бастырырга һәм Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. «Торак - коммуналь хуҗалык һәм төзелеш үзәге» АҖнә әлеге карар басылып чыккан көннән бер ай эчендә Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәренең Горький урамы 35А номерлы күпфатирлы йорттагы торак биналарның милекчеләренә әлеге йортны авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип тану турында язма рәвештә мәгълүмат җиткерергә тәкъдим итәргә.

4. Гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча авария хәлендәге тораktан Лениногорск муниципаль районы маневр фондына күчерүне Россия Федерациясе Торак кодексының 89 статьясында билгеләнгән тәртиптә әлеге карарның рәсми сайтында басылып чыккан көннән алып 1 (бер) ел дәвамында гамәлгә ашырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны ТР «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары А.Ю. Корноуховка йөкләргә.

Җитәкче З.Г. Михайлова

Ф.М. Фәрхетдинов
5-76-90